ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

17.11.2021　　　　с. Введенская Слобода　　　　№17

«Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Петропавловская Слобода авылында гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Карар бирәм:

1.Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Петропавловская Слобода авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2021 елның 28 ноябренә билгеләргә.

Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Петропавловская Слобода авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Петропавловская Слобода авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү

«ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК»

3. Петропавловская Слобода авылы, Слободская урамы, 25 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт яны территориясендә гражданнар җыенын 13: 30 сәгатьтә үткәрергә.

4. Халык җыенын Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　Д.В. Морозов